# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Аерым муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору һәм "Тәтеш муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 22 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Тәтеш муниципаль районы составына керүче түбәндәге муниципаль берәмлекләрне:

1) "Кече Бисәр авыл җирлеге"н һәм "Олы Шәмәк авыл җирлеге"н әлеге җирлекләр халкының тавыш бирү юлы белән белдерелгән ризалыгы нигезендә "Олы Шәмәк авыл җирлеге"нә берләштерү юлы белән үзгәртеп корырга, административ үзәге Олы Шәмәк авылында;

2) "Кече Әтрәч авыл җирлеге"н һәм "Зур Әтрәч авыл җирлеге"н әлеге җирлекләр халкының тавыш бирү юлы белән белдерелгән ризалыгы нигезендә "Зур Әтрәч авыл җирлеге"нә берләштерү юлы белән үзгәртеп корырга, административ үзәге Зур Әтрәч авылында;

3) "Башчы авыл җирлеге"н һәм "Сөендек авыл җирлеге"н әлеге җирлекләр халкының тавыш бирү юлы белән белдерелгән ризалыгы нигезендә "Сөендек авыл җирлеге"нә берләштерү юлы белән үзгәртеп корырга, административ үзәге Сөендек авылында;

4) "Яңа Льяшево Пүчинкәсе авыл җирлеге"н һәм "Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге"н әлеге җирлекләр халкының тавыш бирү юлы белән белдерелгән ризалыгы нигезендә "Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге"нә берләштерү юлы белән үзгәртеп корырга, административ үзәге Кошки-Новотимбаево авылында;

5) "Алекина Поляна авыл җирлеге"н һәм "Федоровка авыл җирлеге"н әлеге җирлекләр халкының тавыш бирү юлы белән белдерелгән ризалыгы нигезендә "Федоровка авыл җирлеге"нә берләштерү юлы белән үзгәртеп корырга, административ үзәге Федоровка авылында;

6) "Чуаш Чурапаны авыл җирлеге"н һәм "Бакырчы авыл җирлеге"н әлеге җирлекләр халкының тавыш бирү юлы белән белдерелгән ризалыгы нигезендә "Бакырчы авыл җирлеге"нә берләштерү юлы белән үзгәртеп корырга, административ үзәге Бакырчы авылында.

**2 статья**

1. "Олы Шәмәк авыл җирлеге", "Зур Әтрәч авыл җирлеге", "Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге", "Федоровка авыл җирлеге", "Сөендек авыл җирлеге", "Бакырчы авыл җирлеге" яңа төзелгән муниципаль берәмлекләренең (алга таба – яңа төзелгән муниципаль берәмлекләр) беренче чакырылыш вәкиллекле органнарының һәм аларның башлыкларының вәкаләтләре срогын биш ел дип билгеләргә.

2. Яңа төзелгән муниципаль берәмлекләрнең беренче чакырылыш вәкиллекле органнары җиде депутаттан тора дип билгеләргә.

3. Яңа төзелгән "Олы Шәмәк авыл җирлеге", "Зур Әтрәч авыл җирлеге", "Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге", "Федоровка авыл җирлеге", "Сөендек авыл җирлеге", "Бакырчы авыл җирлеге" муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына сайлауларны билгеләү, сайлауларны әзерләү һәм уздыру законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.

**3 статья**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 34 статьясындагы 5 өлешендә каралган тәртиптә җирле референдумда кабул ителә торган муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары структурасы турындагы карарда башкасы билгеләнмәсә, түбәндәгеләрне билгеләргә:

1) яңа төзелгән муниципаль берәмлек башлыгы әлеге муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан яшерен тавыш бирү юлы белән үз составыннан сайлана.

Яңа төзелгән "Олы Шәмәк авыл җирлеге", "Зур Әтрәч авыл җирлеге", "Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге", "Федоровка авыл җирлеге", "Сөендек авыл җирлеге", "Бакырчы авыл җирлеге" муниципаль берәмлекләренең һәрберсенең беренче чакырылыш вәкиллекле органы депутаты вәкиллекле орган депутатларының билгеләнгән санының яртысыннан артыграгы аны сайлау өчен тавыш бирсә, әлеге муниципаль берәмлек башлыгы итеп сайланган дип санала.

Яңа төзелгән "Олы Шәмәк авыл җирлеге", "Зур Әтрәч авыл җирлеге", "Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге", "Федоровка авыл җирлеге", "Сөендек авыл җирлеге", "Бакырчы авыл җирлеге" муниципаль берәмлекләренең һәрберсенең башлыгын сайлаганчы әлеге муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы утырышын вәкиллекле органның иң өлкән яшьтәге депутаты ача һәм алып бара;

2) Яңа төзелгән "Олы Шәмәк авыл җирлеге", "Зур Әтрәч авыл җирлеге", "Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге", "Федоровка авыл җирлеге", "Сөендек авыл җирлеге", "Бакырчы авыл җирлеге" муниципаль берәмлекләренең һәрберсенең сайланган башлыгы әлеге муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы рәисе вәкаләтләрен башкара.

**4 статья**

"Тәтеш муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" 2005 елның 31 гыйнварындагы 41-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (III өлеш); 2008, № 12 (IV өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:

а) өченче, унөченче, егерме икенче, егерме өченче, егерме җиденче, утыз өченче абзацларны үз көчен югалткан дип танырга;

б) бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Бакырчы авыл җирлеге: Бакырчы (административ үзәк), Үтәмеш, Татар Чагылдымы, Чуаш Чагылдымы, Чуаш Чурапаны авыллары, Татар Чурапаны поселогы; ";

в) тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Зур Әтрәч авыл җирлеге: Зур Әтрәч (административ үзәк), Кече Әтрәч, Никифоровка авыллары; ";

г) уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Олы Шәмәк авыл җирлеге: Олы Шәмәк (административ үзәк), Кече Бисәр авыллары, Победа поселогы; ";

д) унтугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге: Кошки-Новотимбаево (административ үзәк), Яңа Льяшево Пүчинкәсе, Ивановка, Максимовка, Салмановка, Иске Колмәт, Чуаш Тайбасы авыллары; ";

е) егерме сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Сөендек авыл җирлеге: Сөендек (административ үзәк), Башчы авыллары;";

ж) утыз беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Федоровка авыл җирлеге: Федоровка (административ үзәк), Алекина Поляна, Удельное Нечасово, Кызыл Йолдыз, Красное Нечасово авыллары; ";

2) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта

# «Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре карта-схемасы




Шартлы билгеләр

- республика чиге
- муниципаль район чиге
10 - тоташу ноктасының тәртип саны
10 - җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлек үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| 50(3)-67(4) | - Ульяновск өлкәсе |
| 67(4)-19(36) | - Буа муниципаль районы |
| 2(35)-19(36) | - Апас муниципаль районы |
| 28(34)-2(35) | - Кама Тамагы муниципаль районы |
| 50(3)-28(34) | - Спас муниципаль районы |

"Тәтеш муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Тәтеш шәһәре |
| 2 | Алабирде авыл җирлеге |
| 3 | Байраш авыл җирлеге |
| 4 | Бакырчы авыл җирлеге |
| 5 | Бидәңге авыл җирлеге |
| 6 | Бессоново авыл җирлеге |
| 7 | Богдашкино авыл җирлеге |
| 8 | Зур Әтрәч авыл җирлеге |
| 9 | Олы Тархан авыл җирлеге |
| 10 | Олы Тормы авыл җирлеге |
| 11 | Олы Шәмәк авыл җирлеге |
| 12 | Жуково авыл җирлеге |
| 13 | Ивановка авыл җирлеге |
| 14 | Килдеш авыл җирлеге |
| 15 | Киртәле авыл җирлеге |
| 16 | Keләш авыл җирлеге |
| 17 | Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге |
| 18 | Лаптевка авыл җирлеге |
| 19 | Льяшево авыл җирлеге |
| 20 | Кече Шәмәк авыл җирлеге |
| 21 | Монастырский авыл җирлеге |
| 22 | Нармонка авыл җирлеге |
| 23 | Сөендек авыл җирлеге |
| 24 | Тоншерма авыл җирлеге |
| 25 | Урюм авыл җирлеге |
| 26 | Федоровка авыл җирлеге |
| 27 | Чинчурино авыл җирлеге"; |

3) 4 нче кушымтада:

а) икенче абзацта ", Кече Әтрәч" сүзләрен төшереп калдырырга;

б) бишенче абзацта "Алабирде, Байраш һәм Кече Әтрәч" сүзләрен "Алабирде, Байраш һәм Зур Әтрәч" сүзләренә алмаштырырга;

в) алтынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

г) җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Алабирде авыл җирлеге чиге Зур Әтрәч авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 7 нче тоташу ноктасыннан алып, чокырны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 750 м көнчыгышка таба, 500 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 2,6 км төньяк-көнчыгышка таба уза, аннары, "Апас – Тәтеш" - Алабирде – Кече Әтрәч автомобиль юлын һәм Шонга елгасын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Алабирде, Зур Әтрәч һәм Льяшево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Зур Әтрәч авылыннан 2,3 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 10 нчы тоташу ноктасына кадәр бара. ";

4) 5 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

5) 6 нчы кушымтада:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Байраш авыл җирлеге Алабирде, Зур Әтрәч, Олы Тормы авыл җирлекләре һәм Апас муниципаль районы белән чиктәш. ";

б) дүртенче абзацта "Байраш, Кече Әтрәч авыл җирлекләре һәм Апас муниципаль районы чикләре тоташкан урында" сүзләрен "Байраш, Зур Әтрәч авыл җирлекләре һәм Апас муниципаль районы чикләре тоташкан урында" сүзләренә алмаштырырга;

в) бишенче абзацта "Кече Әтрәч авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Алабирде, Байраш һәм Кече Әтрәч авыл җирлекләре" сүзләрен "Зур Әтрәч авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Алабирде, Байраш һәм Зур Әтрәч авыл җирлекләре" сүзләренә алмаштырырга;

6) 7 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Тәтеш муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең<br>һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең<br>территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның<br>статусы турында" Татарстан Республикасы Законына<br>7 нче кушымта

**Тәтеш муниципаль районының<br>"Бакырчы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге<br>территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Бакырчы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасы тасвирламасы булып тора ("Тәтеш муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта).

Бакырчы авыл җирлеге Бидәңге, Олы Тархан, Кошки-Новотимбаево, Сөендек авыл җирлекләре һәм Буа муниципаль районы белән чиктәш.

**Тәтеш муниципаль районының "Бакырчы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чиге**

Бакырчы авыл җирлеге чиге Буа муниципаль районы белән чиктәш җирдә Бакырчы, Сөендек авыл җирлекләре һәм Буа муниципаль районы чикләре тоташкан урында Чуаш Чагылдымы авылыннан 2,3 км көньяк-көнбатышта Зөя елгасы үзәнендә урнашкан 60 нчы тоташу ноктасыннан алып Тәтеш муниципаль районы чиге буйлап Бакырчы, Кошки-Новотимбаево авыл җирлекләре һәм Буа муниципаль районы чикләре тоташкан урында Кошки-Новотимбаево авылыннан 2,4 км төньяк-көнбатышта урнашкан 43 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Бакырчы авыл җирлеге чиге Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 43 нче тоташу ноктасыннан алып Килнә елгасы агымы буенча 4,6 км аска таба уза, аннары 2,2 км көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, "Киртәле – Рус Киштәге" – Чуаш Чурапаны автомобиль юлын кисеп үтеп, 660 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 1,4 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң 2,6 км көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, аннары Бидәңге елгасы агымы буенча 250 м аска таба Бакырчы, Олы Тархан һәм Кошки-Новотимбаево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Үтәмеш авылыннан 500 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 53 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Бакырчы авыл җирлеге чиге Олы Тархан авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 53 нче тоташу ноктасыннан алып кибеп баручы инеш агымы буенча 1,2 км өскә таба уза, аннары 1,6 км көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң, Олы Тархан - Иске Борындык автомобиль юлын кисеп үтеп, 3,5 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 900 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Бакырчы, Бидәңге һәм Олы Тархан авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Татар Бидәңгесе авылыннан 1,6 км көнчыгышта урнашкан 58 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Бакырчы авыл җирлеге чиге Бидәңге авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 58 нче тоташу ноктасыннан алып, Татар Бидәңгесе - Үтәмеш профильле автомобиль юлын һәм Бидәңге елгасын кисеп үтеп, 3,8 км төньяк-көнбатыш юнәлештә авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, аннары 500 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң 750 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Бакырчы, Бидәңге һәм Сөендек авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Бакырчы авылыннан 2,2 км көнбатышта урнашкан 59 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Бакырчы авыл җирлеге чиге Сөендек авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 59 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,3 км төньяк-көнбатышка таба, 150 м төньяк-көнчыгышка таба, 150 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 150 м төньяк-көнчыгышка таба "Буа урманчылыгы" Татарстан Республикасы

дәүләт бюджет учреждениесенең Буа участок урманчылыгындагы 99 нчы урман кварталына кадәр уза, аннары шушы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 500 м төньяк-көнбатышка таба Зөя елгасына кадәр, 60 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.";

7) 8 нче кушымтада:

а) икенче абзацта "Башчы" сүзен "Сөендек" сүзенә алмаштырырга;

б) дүртенче абзацта "Башчы" сүзен "Сөендек" сүзенә алмаштырырга;

в) бишенче абзацта "Башчы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә" сүзләрен "Сөендек авыл җирлеге белән чиктәш җирдә" сүзләренә, "Башчы авыл җирлекләре" сүзләрен "Сөендек авыл җирлекләре" сүзләренә алмаштырырга;

8) 11 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Тәтеш муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең
һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның
статусы турында" Татарстан Республикасы Законына
11 нче кушымта

**Тәтеш муниципаль районының
"Зур Әтрәч авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге
территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Зур Әтрәч авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасы тасвирламасы булып тора ("Тәтеш муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта).

Зур Әтрәч авыл җирлеге Алабирде, Байраш, Лаптевка, Льяшево, Монастырский авыл җирлекләре, Апас һәм Кама Тамагы муниципаль районнары белән чиктәш.

**Тәтеш муниципаль районының
"Зур Әтрәч авыл җирлеге"
муниципаль берәмлеге территориясе чиге**

Зур Әтрәч авыл җирлеге чиге Апас муниципаль районы белән чиктәш җирдә Байраш, Зур Әтрәч авыл җирлекләре һәм Апас муниципаль районы чикләре тоташкан урында Никифоровка авылыннан 1,3 км көнбатышта урнашкан 1 нче тоташу ноктасыннан алып Тәтеш муниципаль районы чиге буйлап Зур Әтрәч авыл

җирлеге, Апас һәм Кама Тамагы муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Кече Әтрәч авылыннан 3,8 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 2 нче (35 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Зур Әтрәч авыл җирлеге чиге Кама Тамагы муниципаль районы белән чиктәш җирдә 2 нче (35 нче) тоташу ноктасыннан алып Тәтеш муниципаль районы чиге буйлап Зур Әтрәч, Лаптевка авыл җирлекләре һәм Кама Тамагы муниципаль районы чикләре тоташкан урында Лаптевка авылыннан 2,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 3 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Зур Әтрәч авыл җирлеге чиге Лаптевка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 3 нче тоташу ноктасыннан алып гомуми юнәлештә көньяк-көнбатышка таба "Тәтеш урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Келәр участок урманчылыгындагы 47 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап инешкә кадәр уза, шуннан соң шушы инеш агымы буенча 670 м өскә таба ул бүтән инешкә койган җиргә кадәр уза, аннары шушы инеш агымы буенча 560 м өскә таба бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 450 м көньяк-көнчыгышка таба, 1,5 км көньяк-көнбатышка таба уза, аннары көньяк-көнчыгыш юнәлештә 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап һәм 200 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң гомуми юнәлештә 250 м көньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, "Тәтеш – Кама Тамагы" – Монастырский - Лаптевка автомобиль юлын кисеп үтеп, 900 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, аннары, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 100 м урман массивы буйлап һәм 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Зур Әтрәч, Лаптевка һәм Монастырский авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Баймәт авылыннан 2,7 км көньяк-көнбатышта урнашкан 12 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Зур Әтрәч авыл җирлеге чиге Монастырский авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 12 нче тоташу ноктасыннан алып 50 м көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап "Тәтеш - Кама Тамагы" - Монастырский - Лаптевка автомобиль юлына кадәр уза, аннары әлеге автомобиль юлы буйлап 950 м көньякка таба бара, шуннан соң көнбатышка таба борыла һәм 20 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап "Тәтеш урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 2 нче урман кварталына кадәр бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 2,0 км "Тәтеш урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 2, 4 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 150 м "Тәтеш урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 4 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап "Тәтеш шәһәре" муниципаль берәмлеге, Зур Әтрәч, Льяшево һәм Монастырский авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Монастырский авылыннан 2,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 11 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Зур Әтрәч авыл җирлеге чиге Льяшево авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 11 нче тоташу ноктасыннан алып 150 м төньяк-көнбатышка таба "Тәтеш урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 4 нче урман кварталы буйлап һәм 100 м авыл хуҗалыгы

җирләре буйлап уза, аннары, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, "Тәтеш урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 4 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш һәм төньяк чикләре буйлап уза, шуннан соң 1,2 км төньяк-көнбатыш юнәлештә "Тәтеш урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 2 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап һәм, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 1,5 км "Тәтеш урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 1 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м көньяк-көнбатышка таба һәм 13 м төньяк-көнбатышка таба Алабирде, Зур Әтрәч һәм Льяшево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Зур Әтрәч авылыннан 2,3 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 10 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Зур Әтрәч авыл җирлеге чиге Алабирде авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Алабирде, Байраш һәм Зур Әтрәч авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Никифоровка авылыннан 1,4 км көньяк-көнбатышта урнашкан 7 нче тоташу ноктасыннан алып, чокырны кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 750 м көньякка таба, 500 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 2,6 км төньяк-көнчыгышка таба уза, аннары, "Апас - Тәтеш" - Алабирде - Кече Әтрәч автомобиль юлын һәм Шонга елгасын кисеп үтеп, 6,5 км көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 10 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Зур Әтрәч авыл җирлеге чиге Байраш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 7 нче тоташу ноктасыннан алып Үләмә елгасы агымы буенча 2,4 км аска таба 1 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

9) 12 нче кушымтада:

а) икенче абзацта "Яңа Льяшево Пүчинкәсе" сүзләрен "Кошки-Новотимбаево" сүзләренә алмаштырырга;

б) җиденче абзацта "Яңа Льяшево Пүчинкәсе" сүзләрен "Кошки-Новотимбаево" сүзләренә алмаштырырга;

в) сигезенче абзацта "Яңа Льяшево Пүчинкәсе авыл җирлеге белән чиктәш җирдә" сүзләрен "Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге белән чиктәш җирдә" сүзләренә, "Олы Тархан, Киртәле һәм Яңа Льяшево Пүчинкәсе авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында" сүзләрен "Олы Тархан, Киртәле һәм Кошки-Новотимбаево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында" сүзләренә алмаштырырга;

10) 14 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Тәтеш муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең
һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның
статусы турында" Татарстан Республикасы Законына
14 нче кушымта

**Тәтеш муниципаль районының "Олы Шәмәк авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Олы Шәмәк авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасы тасвирламасы булып тора ("Тәтеш муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта).

Олы Шәмәк авыл җирлеге Олы Тормы, Келәш, Льяшево, Кече Шәмәк һәм Чинчурино авыл җирлекләре белән чиктәш.

**Тәтеш муниципаль районының "Олы Шәмәк авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чиге**

Олы Шәмәк авыл җирлеге чиге Кече Шәмәк авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Олы Тормы, Олы Шәмәк һәм Кече Шәмәк авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кече Тормы авылыннан 200 м көньякта урнашкан 15 нче тоташу ноктасыннан алып Шанчисерма елгасы агымы буенча 2,3 км өскә таба уза, аннары 220 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 440 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң 540 м көньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк чиге буйлап, 1,7 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 340 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 2,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 470 м урман массивының көнбатыш чиге буйлап Олы Шәмәк, Келәш, Кече Шәмәк авыл җирлекләре һәм Буа муниципаль районы чикләре тоташкан урында Победа поселогыннан 2,8 км төньяк-көнбатышта урнашкан 18 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Олы Шәмәк авыл җирлеге чиге Олы Тормы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Олы Тормы, Олы Шәмәк һәм Льяшево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Олы Шәмәк авылыннан 2,0 км көнчыгышта урнашкан 17 нче тоташу ноктасыннан алып 1,1 км төньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм, Чукасы инешен кисеп үтеп, 1,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Тормы елгасына кадәр уза, аннары Тормы елгасы агымы буенча 3,8 км өскә таба 15 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Олы Шәмәк авыл җирлеге чиге Льяшево авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 17 нче тоташу ноктасыннан алып 560 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм, "Апас - Тәтеш" - Олы Шәмәк - Кече Шәмәк автомобиль юлын кисеп үтеп, 2,6 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан

соң 1,5 км көньяк-көнчыгыш юнәлештә урман полосасының көнбатыш чиге буйлап бара, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 1,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Олы Шәмәк, Льяшево һәм Чинчурино авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кече Бисәр авылыннан 1,6 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 22 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Олы Шәмәк авыл җирлеге чиге Чинчурино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 22 нче тоташу ноктасыннан алып 1,1 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 810 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап "Буа - Тәтеш" - Кушкуй автомобиль юлына кадәр бара, әлеге автомобиль юлы буйлап 1,1 км көнбатышка таба инешкә кадәр уза, шуннан соң инеш агымы буенча 850 м аска таба икенче инеш белән кушылган җиргә кадәр бара, аннары шушы инеш агымы буенча 3,5 км өскә таба "Тәтеш урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 18 нче урман кварталына кадәр уза, 200 м көньяк-көнбатышка таба шушы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм 120 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң 50 м көньяк-көнчыгышка таба "Тәтеш урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 18 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, 80 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм "Тәтеш урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 19 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 250 м уза, шушы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 260 м көньяк-көнбатышка таба һәм 200 м көньяк-көнчыгышка таба бара, аннары 880 м көньяк-көнбатышка таба "Тәтеш урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 19, 20 нче урман кварталларының көньяк чиге буйлап Олы Шәмәк, Келәш һәм Чинчурино авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кушкуй авылыннан 2,2 км көньяк-көнбатышта урнашкан 31 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Олы Шәмәк авыл җирлеге чиге Келәш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 18 нче тоташу ноктасыннан алып 630 м көньяк-көнбатышка таба "Тәтеш урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 8 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, 400 м шушы урман кварталы буйлап уза, аннары 190 м көньяк-көнчыгышка таба шушы урман кварталының көньяк чиге буйлап, 310 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 110 м урман массивының төньяк чиге буйлап һәм 610 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 1,8 км көньяк-көнбатышка таба "Тәтеш урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 10, 13, 16 нчы урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 1,6 км көньяк-көнчыгышка таба 16 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм 1,0 км төньякка таба көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң 240 м төньяк-көнчыгышка таба "Тәтеш урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 14 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, шушы инеш агымы буенча 2,0 км аска таба бара, аннары гомуми юнәлештә 3,0 км төньяк-көнчыгышка таба "Тәтеш урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы

17 нче урман кварталы чиге буйлап бара, шуннан соң 910 м көньяк-көнбатышка таба "Тәтеш урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 18 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, аннары 90 м көньяк-көнчыгышка таба шушы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм 1,7 км "Тәтеш урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 19, 20 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап 31 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

11) 15 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

12) 16 нчы кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Тәтеш муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең<br>һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең<br>территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның<br>статусы турында" Татарстан Республикасы Законына<br>16 нчы кушымта

**Тәтеш муниципаль районының<br>"Жуково авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе<br>чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Жуково авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасы тасвирламасы булып тора ("Тәтеш муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта).

Жуково авыл җирлеге Богдашкино, Килдеш, Кошки-Новотимбаево, Урюм һәм Федоровка авыл җирлекләре белән чиктәш.

**Тәтеш муниципаль районының<br>“Жуково авыл җирлеге”<br>муниципаль берәмлеге территориясе чиге**

Жуково авыл җирлеге чиге Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Жуково, Кошки-Новотимбаево һәм Федоровка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Сумароков авылыннан 1,6 км төньяк-көнбатышта урнашкан 39 нчы тоташу ноктасыннан алып 220 м көньяк-көнчыгышка таба "Буа урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Буа участок урманчылыгындагы 89 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап һәм 160 м буа буйлап уза, аннары, инешне кисеп үтеп, 700 м көньяк-көнбатыш юнәлештә "Буа урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Буа участок урманчылыгындагы 89, 90 нчы урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап һәм буаның көнчыгыш кырые буйлап 190 м

инешкә кадәр, шуннан соң инеш агымы буенча 1,4 км аска таба бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,2 км көньяк-көнбатышка таба, 2,78 км көньякка таба, 900 м көньяк-көнчыгышка таба, 250 м көнчыгышка таба һәм 460 м көньякка таба Килнә елгасына кадәр бара, шушы елга агымы буенча 350 м өскә таба уза, аннары 1,6 км көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Жуково, Килдеш һәм Кошки-Новотимбаево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кызыл Тархан авылыннан 1,5 км көньяк-көнбатышта урнашкан 44 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Жуково авыл җирлеге чиге Федоровка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Богдашкино, Жуково һәм Федоровка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ивановка авылыннан 3,8 км көнбатышта урнашкан 36 нчы тоташу ноктасыннан алып 1,7 км көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 1,1 км көньяк-көнбатышка таба "Тәтеш урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 65 нче урман кварталы буйлап, аннары 550 м көньяк-көнбатыш юнәлештә шушы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,0 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм, инешне кисеп үтеп, 1,5 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м көнбатышка таба, 380 м көньяк-көнбатышка таба, 30 м төньякка таба, 1,3 км төньяк-көнбатышка таба һәм, Жуково - Кызыл Йолдыз автомобиль юлын кисеп үтеп, 150 м көньяк-көнбатышка таба кибеп баручы инешкә кадәр бара, кибеп баручы инеш агымы буенча 4,1 км өскә таба уза, шуннан соң, Кызыл Йолдыз - Яңа Сумароков автомобиль юлын кисеп үтеп, 900 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 650 м төньяк-көнбатышка таба һәм, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 350 м төньяк-көнчыгышка таба, шуннан соң 200 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,1 км уза, аннары 1,1 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм "Буа урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Буа участок урманчылыгындагы 89 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап 39 нчы тоташу ноктасына кадәр 1,3 км бара.

Жуково авыл җирлеге чиге Богдашкино авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 36 нчы тоташу ноктасыннан алып 1,5 км көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 2,8 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап 950 м һәм авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Килнә елгасына кадәр 500 м бара, шуннан соң шушы елга агымы буенча 250 м аска таба Богдашкино, Жуково һәм Урюм авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иоково авылыннан 1,0 км көньяк-көнчыгышта Килнә елгасы үзәнендә урнашкан 45 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Жуково авыл җирлеге чиге Урюм авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 45 нче тоташу ноктасыннан алып Килнә елгасы агымы буенча 2,1 км аска таба Жуково, Килдеш һәм Урюм авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Берлек авылыннан 980 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 46 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Жуково авыл җирлеге чиге Килдеш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 46 нчы тоташу ноктасыннан алып Килнә елгасы агымы буенча 1,6 км аска таба уза, аннары

көньяк-көнчыгышка таба 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм Берлек авылының көнчыгыш чигеннән 200 м бара, шуннан соң 550 м көньяк-көнбатышка таба Берлек авылының көньяк чигеннән уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 80 м төньяк-көнбатышка таба һәм 60 м көньяк-көнбатышка таба озын чокырга кадәр уза, гомуми юнәлештә төньяк-көнбатышка таба озын чокыр буйлап Килнә елгасына кадәр бара, шуннан соң, дамбаны кисеп чыгып, Килнә елгасы агымы буенча 1,3 км аска таба Килнә елгасына Киртәле инеше койган җиргә кадәр уза, аннары, "Тәтеш - Олы Тархан - Ундоры" - Жуково - Иоково автомобиль юлын кисеп үтеп, Киртәле инеше агымы буенча 650 м өскә таба кибеп баручы инеш белән кушылган җиргә кадәр бара, кибеп баручы инеш агымы буенча 1,8 км өскә таба бара, шуннан соң 150 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 450 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 140 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 350 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм 360 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Киртәле инешенә кадәр уза, аннары Киртәле инеше агымы буенча 430 м аска таба бара, шуннан соң 1,6 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 100 м төньякка таба урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, аннары 2,2 км көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 44 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

13) 18 нче кушымтада:

а) икенче абзацта "Яңа Льяшево Пүчинкәсе" сүзләрен "Кошки-Новотимбаево" сүзләренә алмаштырырга;

б) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Килдеш авыл җирлеге чиге Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Жуково, Килдеш һәм Кошки-Новотимбаево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кызыл Тархан авылыннан 1,5 км көньяк-көнбатышта урнашкан 44 нче тоташу ноктасыннан алып, Киртәле - Рус Киштәге автомобиль юлын кисеп үтеп, 1,5 км көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Килдеш, Киртәле һәм Кошки-Новотимбаево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Түбән Тархан авылыннан 2,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 56 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.";

14) 19 нчы кушымтада:

а) икенче абзацта "Яңа Льяшево Пүчинкәсе" сүзләрен "Кошки-Новотимбаево" сүзләренә алмаштырырга;

б) бишенче абзацта "Яңа Льяшево Пүчинкәсе" сүзләрен "Кошки-Новотимбаево" сүзләренә алмаштырырга;

в) алтынчы абзацта "Яңа Льяшево Пүчинкәсе авыл җирлеге белән чиктәш җирдә" сүзләрен "Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге белән чиктәш җирдә"

сүзләренә, "Яңа Льяшево Пучинкәсе авыл җирлекләре" сүзләрен "Кошки-Новотимбаево авыл җирлекләре" сүзләренә алмаштырырга;

15) 20 нче кушымтада:

а) икенче абзацта "Кече Бисәр," сүзләрен төшереп калдырырга;

б) бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Келәш авыл җирлеге чиге Олы Шәмәк авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 18 нче тоташу ноктасыннан алып 630 м көньяк-көнбатышка таба "Тәтеш урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 8 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, 400 м шушы урман кварталы буйлап уза, аннары 190 м көньяк-көнчыгышка таба шушы урман кварталының көньяк чиге буйлап, 310 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 110 м урман массивының төньяк чиге буйлап һәм 610 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 1,8 км көньяк-көнбатышка таба "Тәтеш урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 10, 13, 16 нчы урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 1,6 км көньяк-көнчыгышка таба 16 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм 1,0 км төньякка таба көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң 240 м төньяк-көнчыгышка таба "Тәтеш урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 14 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, шушы инеш агымы буенча 2,0 км аска таба бара, аннары гомуми юнәлештә 3,0 км төньяк-көнчыгышка таба "Тәтеш урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 17 нче урман кварталы чиге буйлап бара, шуннан соң 910 м көньяк-көнбатышка таба "Тәтеш урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 18 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, аннары 90 м көньяк-көнчыгышка таба шушы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм 1,7 км "Тәтеш урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 19, 20 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап Олы Шәмәк, Келәш һәм Чинчурино авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кушкуй авылыннан 2,2 км көньяк-көнбатышта урнашкан 31 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

в) алтынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

16) 21 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Тәтеш муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең<br>һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең<br>территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның<br>статусы турында" Татарстан Республикасы Законына<br>21 нче кушымта

## Тәтеш муниципаль районының "Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы

Әлеге картографик тасвирлама "Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасы тасвирламасы булып тора ("Тәтеш муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта).

Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге Бакырчы, Олы Тархан, Жуково, Килдеш, Киртәле, Федоровка авыл җирлекләре һәм Буа муниципаль районы белән чиктәш.

## Тәтеш муниципаль районының "Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чиге

Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге чиге Буа муниципаль районы белән чиктәш җирдә Бакырчы, Кошки-Новотимбаево авыл җирлекләре һәм Буа муниципаль районы чикләре тоташкан урында Кошки-Новотимбаево авылыннан 2,4 км төньяк-көнбатышта урнашкан 43 нче тоташу ноктасыннан алып Тәтеш муниципаль районы чиге буйлап Кошки-Новотимбаево, Федоровка авыл җирлекләре һәм Буа муниципаль районы чикләре тоташкан урында Яңа Сумароков авылыннан 2,4 км төньяк-көнбатышта урнашкан 40 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге чиге Федоровка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Жуково, Кошки-Новотимбаево һәм Федоровка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Сумароков авылыннан 1,6 км төньяк-көнбатышта урнашкан 39 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 860 м төньяк-көнбатышка таба, 160 м төньяк-көнчыгышка һәм 180 м төньяк-көнбатышка таба 40 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге чиге Жуково авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 39 нчы тоташу ноктасыннан алып 220 м көньяк-көнчыгышка таба "Буа урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Буа участок урманчылыгындагы 89 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап һәм 160 м буа буйлап уза, аннары, инешне кисеп үтеп, 700 м көньяк-көнбатыш юнәлештә "Буа урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Буа участок урманчылыгындагы 89, 90 нчы урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап һәм буаның көнчыгыш кырые буйлап 190 м инешкә кадәр, шуннан соң инеш агымы буенча 1,4 км аска таба бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,2 км көньяк-көнбатышка таба, 2,78 км көньякка таба, 900 м көньяк-көнчыгышка таба, 250 м көнчыгышка таба һәм 460 м көньякка таба Килнә елгасына кадәр бара, шушы елга агымы буенча 350 м өскә таба уза, аннары 1,6 км көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Жуково, Килдеш һәм Кошки-Новотимбаево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кызыл

Тархан авылыннан 1,5 км көньяк-көнбатышта урнашкан 44 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге чиге Килдеш авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 44 нче тоташу ноктасыннан алып, Киртәле – Рус Киштәге автомобиль юлын кисеп үтеп, 1,5 км көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Килдеш, Киртәле һәм Кошки-Новотимбаево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Түбән Тархан авылыннан 2,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 56 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге чиге Киртәле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 56 нчы тоташу ноктасыннан алып, инешне кисеп үтеп, 2,2 км көньяк-көнбатышка таба Олы Тархан, Киртәле һәм Кошки-Новотимбаево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Түбән Тархан авылыннан 550 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 54 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге чиге Олы Тархан авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 54 нче тоташу ноктасыннан алып Тархан елгасы агымы буенча 5,3 км аска таба Бидәңге елгасы белән кушылган җиргә кадәр уза һәм Бидәңге елгасы агымы буенча 4,3 км өскә таба Бакырчы, Олы Тархан һәм Кошки-Новотимбаево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Үтәмеш авылыннан 500 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 53 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге чиге Бакырчы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 43 нче тоташу ноктасыннан алып Килнә елгасы агымы буенча 4,6 км аска таба уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 2,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, "Киртәле – Рус Киштәге" – Чуаш Чурапаны автомобиль юлын кисеп үтеп, 660 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 1,4 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң 2,6 км көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, аннары Бидәңге елгасы агымы буенча 250 м аска таба 53 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

17) 22 нче кушымтада:

а) икенче абзацта "Кече Әтрәч," сүзләрен төшереп калдырырга;

б) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Лаптевка авыл җирлеге чиге Зур Әтрәч авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Зур Әтрәч, Лаптевка авыл җирлекләре һәм Кама Тамагы муниципаль районы чикләре тоташкан урында Лаптевка авылыннан 2,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 3 нче тоташу ноктасыннан алып гомуми юнәлештә көньяк-көнбатышка таба "Тәтеш урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Келәр участок урманчылыгындагы 47 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап инешкә кадәр уза, шуннан соң шушы инеш агымы буенча 670 м өскә таба ул бүтән инешкә койган җиргә кадәр уза, аннары шушы инеш агымы буенча 560 м өскә таба бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 450 м көньяк-көнчыгышка таба, 1,5 км көньяк-көнбатышка таба уза, аннары көньяк-көнчыгыш юнәлештә 800 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап һәм 200 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң гомуми

юнәлештә 250 м көньяк-көнбатышка таба урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, "Тәтеш – Кама Тамагы" – Монастырский - Лаптевка автомобиль юлын кисеп үтеп, 900 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, аннары, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 100 м урман массивы буйлап һәм 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Зур Әтрәч, Лаптевка һәм Монастырский авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Баймәт авылыннан 2,7 км көньяк-көнбатышта урнашкан 12 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

в) бишенче абзацны үз көчен югалткан дип таныrга;

18) 23 нче кушымтада:

а) икенче абзацта "Кече Бисәр," сүзләрен төшереп калдырырга;

б) дүртенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

в) бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Льяшево авыл җирлеге чиге Олы Шәмәк авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Олы Тормы, Олы Шәмәк һәм Льяшево авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Олы Шәмәк авылыннан 2,0 км көнчыгышта урнашкан 17 нче тоташу ноктасыннан алып 560 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм, "Апас - Тәтеш" - Олы Шәмәк - Кече Шәмәк автомобиль юлын кисеп үтеп, 2,6 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң 1,5 км көньяк-көнчыгыш юнәлештә урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 1,3 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Олы Шәмәк, Льяшево һәм Чинчурино авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Кече Бисәр авылыннан 1,6 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 22 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

19) 24, 25, 29 нчы кушымталарны үз көчен югалткан дип танырга;

20) 30 нчы кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Тәтеш муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең
һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның
статусы турында" Татарстан Республикасы Законына
30 нчы кушымта

**Тәтеш муниципаль районының**
**"Сөендек авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге**
**территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама "Сөендек авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасы тасвирламасы булып тора ("Тәтеш муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль

берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта).

Сөендек авыл җирлеге Бакырчы, Бидәңге авыл җирлекләре, Буа муниципаль районы һәм Ульяновск өлкәсе белән чиктәш.

**Тәтеш муниципаль районының "Сөендек авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясе чиге**

Сөендек авыл җирлеге чиге Бакырчы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Бакырчы, Бидәңге һәм Сөендек авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Бакырчы авылыннан 2,2 км көнбатышта урнашкан 59 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,3 км төньяк-көнбатышка таба, 150 м төньяк-көнчыгышка таба, 150 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 150 м төньяк-көнчыгышка таба "Буа урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Буа участок урманчылыгындагы 99 нчы урман кварталына кадәр уза, аннары шушы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап 500 м төньяк-көнбатышка таба Зөя елгасына кадәр, Бакырчы, Сөендек авыл җирлекләре һәм Буа муниципаль районы чикләре тоташкан урында Зөя елгасы үзәнендә Чуаш Чагылдымы авылыннан 2,3 км көньяк-көнбатышта урнашкан 60 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Сөендек авыл җирлеге чиге Бидәңге авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 59 нчы тоташу ноктасыннан алып, "Тәтеш – Олы Тархан - Ундоры" - Сөендек автомобиль юлын кисеп үтеп, көньяк-көнбатышка таба 6,7 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Бидәңге, Сөендек авыл җирлекләре һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Башчы авылыннан 2,7 км көньякта урнашкан 68 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Сөендек авыл җирлеге чиге Ульяновск өлкәсе белән чиктәш җирдә 68 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Сөендек авыл җирлеге, Буа муниципаль районы һәм Ульяновск өлкәсе чикләре тоташкан урында Сөендек авылыннан 4,1 км төньяк-көнбатышта урнашкан 67 нче (4 нче) тоташу ноктасына кадәр уза.

Сөендек авыл җирлеге чиге Буа муниципаль районы белән чиктәш җирдә 67 нче (4 нче) тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба Тәтеш муниципаль районы чиге буйлап 60 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.";

21) 33 нче кушымтада:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Федоровка авыл җирлеге Богдашкино, Жуково, Келәш, Кошки-Новотимбаево, Нармонка, Чинчурино авыл җирлекләре һәм Буа муниципаль районы белән чиктәш.";

б) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Федоровка авыл җирлеге чиге Буа муниципаль районы белән чиктәш җирдә Кошки-Новотимбаево, Федоровка авыл җирлекләре һәм Буа муниципаль районы чикләре тоташкан урында Яңа Сумароков авылыннан 2,4 км төньяк-көнбатышта

урнашкан 40 нчы тоташу ноктасыннан алып Тәтеш муниципаль районы чиге буйлап Келәш, Федоровка авыл җирлекләре һәм Буа муниципаль районы чикләре тоташкан урында Федоровка авылыннан 3,2 км төньяк-көнбатышта урнашкан 33 нче тоташу ноктасына кадәр уза.";

в) тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Федоровка авыл җирлеге чиге Жуково авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 36 нчы тоташу ноктасыннан алып 1,7 км көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 1,1 км көньяк-көнбатышка таба "Тәтеш урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Тәтеш участок урманчылыгындагы 65 нче урман кварталы буйлап, аннары 550 м көньяк-көнбатыш юнәлештә шушы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,0 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм, инешне кисеп үтеп, 1,5 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 250 м көнбатышка таба, 380 м көньяк-көнбатышка таба, 30 м төньякка таба, 1,3 км төньяк-көнбатышка таба һәм, Жуково - Кызыл Йолдыз автомобиль юлын кисеп үтеп, 150 м көньяк-көнбатышка таба кибеп баручы инешкә кадәр бара, кибеп баручы инеш агымы буенча 4,1 км өскә таба уза, шуннан соң, Кызыл Йолдыз - Яңа Сумароков автомобиль юлын кисеп үтеп, 900 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 650 м төньяк-көнбатышка таба һәм, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 350 м төньяк-көнчыгышка таба, шуннан соң 200 м төньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 1,1 км уза, аннары 1,1 км көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм "Буа урманчылыгы" Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Буа участок урманчылыгындагы 89 нчы урман кварталының төньяк чиге буйлап Жуково, Кошки-Новотимбаево һәм Федоровка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Сумароков авылыннан 1,6 км төньяк-көнбатышта урнашкан 39 нчы тоташу ноктасына кадәр 1,3 км бара.";

г) унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Федоровка авыл җирлеге чиге Кошки-Новотимбаево авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 39 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 860 м төньяк-көнбатышка таба, 160 м төньяк-көнчыгышка һәм 180 м төньяк-көнбатышка таба 40 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.";

22) 34 нче кушымтада:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Чинчурино авыл җирлеге Олы Шәмәк, Келәш, Льяшево, Нармонка һәм Федоровка авыл җирлекләре белән чиктәш.";

б) дүртенче абзацта "Кече Бисәр" сүзләрен "Олы Шәмәк" сүзләренә алмаштырырга;

в) бишенче абзацта "Кече Бисәр авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Льяшево, Кече Бисәр һәм Чинчурино авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында" сүзләрен "Олы Шәмәк авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Олы Шәмәк, Льяшево һәм Чинчурино авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында" сүзләренә алмаштырырга;

23) 35 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

**5 статья**

Әлеге Закон 2010 елның 1 июленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Гомуми бүлек / Общий отдел

Казан, Кремль
2010 елның 22 мае
№ 27-ТРЗ